**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында нигезләмәгә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында» 2014 елның 12 июнендәге ПУ-569 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 27 июнендәге ПУ-604 номерлы, 2015 елның 19 ноябрендәге ПУ-1111 номерлы, 2015 елның 19 декабрендәге ПУ-1228 номерлы, 2017 елның 15 сентябрендәге ПУ-818 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы һәм 2018 елның 21 сентябрендәге ПУ-679 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 4 пунктта:

«к» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«к) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең абруен күтәрү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен кызыксындыру системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;»;

түбәндәге эчтәлекле «к$^1$» пунктчасы өстәргә:

«к$^1$) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасына кертү өчен Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатураларын карап тикшерү һәм тиешле карарлар кабул итү;»;

б) 11 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Совет составында Советның кадрлар буенча комиссиясе (алга таба – Кадрлар комиссиясе) оештырыла, ул әлеге Нигезләмәнең 4 пункты «е», «ж» һәм «к$^1$» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерә.».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасы турында» Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең электрон мактау тактасы турындагы кушымтада бирелүче нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы (алга таба – Кадрлар советы)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советының кадрлар буенча комиссиясе (алга таба – Кадрлар комиссиясе)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 11 пунктта «Кадрлар советын» сүзләрен «Кадрлар комиссиясен» сүзләренә алмаштырырга;

в) 12 пунктта:

беренче абзацта «Кадрлар советы» сүзләрен «Кадрлар комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Кадрлар советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы» сүзләренә алмаштырырга;

г) 13 пунктта «Кадрлар советы» сүзләрен «Кадрлар комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

д) 16 пунктта:

«Кадрлар советы» сүзләрен «Кадрлар комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

«Кадрлар советы» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 18 март
№ ПУ-172